ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАНАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.28, д. им. М. Вахитова,
422575

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КАНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Үзәк ур., 28 нче йорт, М. Вахитов исем авылы,
422575

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30

10.01.2020 д. Канаш №1

## Минималь хезмәт хакы күләме турында

«Хезмәткә түләүнең минималь күләме турында «Федераль законның 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 27 декабрендәге 463-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге бюджет учреждениеләре җитәкчеләренә эш вакыты нормасын эшләгән һәм хезмәт нормаларын (хезмәт бурычларын) үтәгән хезмәткәрләргә билгеләнгән минималь хезмәт хакы күләменнән ким булмаган эш хакы 12 130,00 сум түләүне тәэмин итәргә
2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында шулай ук Канаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Югары Ослан муниципаль район
Канаш авыл җирлеге башлыгы Н.Н.Вальков